| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 24.11.2014** г. Казань **№ 369**

**Коррупция куркынычы белән бәйле дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәрләр Исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июль № 79-ФЗ Федераль законы. «Коррупциягә каршы эшчәнлек турында» 2008 елның 25 декабрь № 273-ФЗ Федераль законы, «Дәүләт вазифаларын башкаручы затларның һәм башка затларның табышларының чыгымнарга туры килүенә контроль турында» 2012 елның 3 декабрь № 230-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнвар № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына билгеләнгәндә Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтен башкаручы хезмәткәрләр үзләренең табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатыннарының (ирләренең), балигъ булмаган балаларының табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә мәҗбүр ителгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәрләр исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрь № УП-701 Указын үтәү өчен,

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) коррупция куркынычы белән бәйле дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәрләрнең күрсәтелгән исемлеген (алга

таба – Исемлек) расларга.  Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәрләрне билгеләнгәндә, гражданнар үзләренең табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатыннарының (ирләренең), балигъ булмаган балаларының табышлары турында, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, Исемлек белән килештереп, белешмәләр бирергә, шулай ук Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаруга билгеләнгәндә, гражданнар үзләренең табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатыннарының (ирләренең), балигъ булмаган балаларының табышлары турында, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, Исемлек белән килештереп,  белешмәләр бирергә тиешләр.

2. Дәүләт комитетының  Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәр, Исемлеккә кертелгән граждан үзенең чыгымнары турында, шулай ук җир участогын, күчемсез милекнең башка обьектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелган) капиталында катнашу өлеше, пайлар) сатып алуда һәр исәп-хисап буенча, әгәр исәп-хисап күләме әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының, алда исәп-хисап ясаганга кадәр соңгы өч елдагы тулаем кеременнән артса, чыгымнары турында һәм исәп-хисап ясау чыганаклары турында белешмәләр бирергә тиешлеген билгеләргә.

3. «Коррупциягә каршы эшчәнлек турында» 2008 елның 25 декабрь № 273-ФЗ Федераль законы нигезендә:

Дәүләт комитетында  Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык  хезмәте вазифасын башкаручы хезмәткәрнең, Исемлеккә кертелгән гражданның, дәүләт хезмәтеннән җибәрелгәннән соң, ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында оешмада вазифаларын башкаруга һәм (яки) Дәүләт комитетында шушы оешма белән дәүләт идарә итүенең  аерым функцияләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре вазифаларына кергән очракта, дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм яклар арасындагы низагны җайга салу буенча Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты комиссиясе рөхсәте белән, шушы оешмада гражданлык-хокукый килешү (гражданлык-хокукый килешүләр) бер ай дәвамында йөз мең сумнан күбрәк бәядәге хезмәтләрне ( шушы оешмага хезмәт күрсәтүне) үти алуын аңлатырга;

Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте хезмәткәре вазифасын башкарган, Исемлеккә кертелгән граждан, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән җибәрелгәннән соң, ике ел дәвамында шушы Боерыкның 3 пункты икенче абзацында каралган хезмәтләр үтәүгә ( хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүләр төзегәндә, эшкә алучы (эш бирүче) вәкилгә үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр бирергә тиеш;

Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте хезмәткәре вазифасын башкарган, Исемлеккә кертелгән гражданның, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән җибәрелгәннән соң, шушы Боерыкның 3 пункты икенче абзацында каралган таләпләрне үтәмәве, күрсәтелгән граждан белән шушы Боерыкның 3 пункты икенче абзацында каралган, хезмәтләр үтәүгә ( хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүләрне туктата ала.

4. «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәр урынына билгеләнгәндә, гражданнар үзләренең табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатыннарының (ирләренең), балигъ булмаган балаларының табышлары турында, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле, шулай ук Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын башкаруга билгеләнгәндә гражданнар үзләренең табышлары турында, милекләре турында һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатыннарының

(ирләренең), балигъ булмаган балаларының табышлары турында, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле булганда, Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифаларын башкаручы хезмәткәрләрнең Исемлеген раслау турында" Татарстан Републикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2013 елның 28 ноябрь № 371 боерыгы үз көчен югалткан дип таныргa;

5. Шушы боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

6. Шушы боерык, рәсми басылгач ун көннән соң, үз көченә керә.

7 . Шушы боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт
комитеты боерыгына кушымта
_______________ № ____

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының коррупция куркынычы белән бәйле дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре Исемлеге**

**1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге хезмәткәрләр:**

1.1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары;
1.2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе урынбасары;
1.3. эшләр белән идарә итүче;
1.4. идарә начальнигы;
1.5. бүлек начальнигы;
1.6. бүлек начальнигы урынбасары.

**2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге хезмәткәрләр:**

2.1. рәис ярдәмчесе.

**3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге хезмәткәрләр:**

3.1. административ практика бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;
3.2. технологик кушылуларга түләүне җайга салу бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.